# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 21 июль, 17 ноябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $15^1$ статьяның 1 өлешендәге 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 16 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

"5. Муниципаль районның җирле администрациясе муниципаль районның административ үзәге булып торган җирлекнең җирле администрациясе вәкаләтләрен әлеге Законның 21 статьясындагы 4 өлешенең өченче абзацында каралган очракларда муниципаль район бюджетының үз керемнәре һәм бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән гамәлгә ашыра.";

3) $17^1$ статьяның 1 өлешендәге 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

4) 18 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

"6$^1$) җирлекләрнең, шәһәр округларының коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерүнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан таләпләр билгеләнә торган программаларын эшләү һәм раслау;".

**2 статья**

1. Әлеге Закон, шушы Законның 1 статьясындагы 4 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пункты "Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2012 елның 30 декабрендәге 289-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы үз көченә кергән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2013 елның 11 марты
№ 17-ТРЗ